| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>**ЛАШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** | | **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>ЧЕРЕМШАНСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**<br>**ЛАШМАНСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** |
|---|---|---|
| 423110, Лашман авылы, Советлар урамы,55А йорт<br>Телефон (84396)2-92-35<br>Факс (84396) 2-92-35<br>Email: Lash.Cmn2@tatar.ru | | 423110. село Лашманка, ул.Советская, д.55А<br>Телефон (84396) 2-92-35<br>Факс (84396) 2-92-35<br>Email: Lash.Cmn2@tatar.ru |


**№ 13** **20 октябрь 2025 ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 18 декабрендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Лашман авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 18 декабрендәге 24 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 бүлегендә 2.5.1 пунктының 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын бирү һәм аларны эшкәртү кирәк булган очракта һәм әгәр федераль закон нигезендә мондый шәхси мәгълүматларны эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булса, муниципаль хезмәт алуны сорап мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән затның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгын алуын раслый торган документлар тапшыра. Ризалык алуны раслый торган документлар шул исәптән электрон документ рәвешендә дә тапшырылырга мөмкин».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районының
Лашман авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Х.Гыйльманова